**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Кили авылы торак пунктында ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**13 ноябрь 2025 ел** **№ 2**

2004 елның 28 нче июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 нче статьясына таянып, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Кили авылы торак пунктында халык җыены **карар бирде**:

1. 90% күләмендә ташлама каралган I нче төркем инвалидларын, Бөек Ватан сугышы ветераннарын, Бөек Ватан сугышы тол хатыннарын, тыл хезмәтчәннәрен, 80 яшьтән узган өлкәннәрне, 70 яшьтән узган балалары булмаган ялгыз яшәүче өлкәннәрне, Россия Федерациясе кораллы көчләрендә мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларын, Россия Федерациясе кораллы көчләрендә контракт буенча хезмәт итүче гражданнарны исәпкә алмаганда, Норма авыл җирлеге Кили авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданнарга 2026 нче елда үзарасалымны 1000 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:
- Г. Тукай һәм Нариман урамнары буйлап юл-урам челтәрен һәм юлларның асфальт-бетон капламын норматив хәлгә китерү.

2) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:
- Новая урамында янгын сүндерү гидранты өчен комплект сатып алу.

3) яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту:
- Кили авылының яр буе зоналарын чистарту.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Норма авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Татарстан Республикасы мунципаль берәмлекләре порталы составындагы baltasi.tatarstan.ru. Балтач муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Норма авыл җирлеге башлыгы Р.Н. Шарипҗанов